УДК 82-95

***Л.Ш. Галиева***

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Статья посвящена исследованию литературно-критического наследия известного поэта-героя Мусы Джалиля (1906–1944), которому в этом году исполняется 120 лет со дня рождения. Несмотря на то, что поэтическое творчество писателя изучено достаточно полно, деятельность М. Джалиля как литературного критика была рассмотрена лишь в нескольких статьях, опубликованных на страницах периодических изданий в 80-е гг. прошлого столетия. Авторами этих публикаций являются Р. Мухамадиев, Ш. Хамматов, А. Махмудов, Р. Мустафин. В данной статье была поставлена цель обобщить имеющиеся сведения о деятельности поэта в этой области и вкратце охарактеризовать его литературно-критическое наследие вне рамок каких-либо общественно-политических явлений. Новизна исследования заключается в том, что статьи М. Джалиля позволяют по-новому взглянуть на некоторые особенности литературного процесса советского периода, они отражают повседневность советских писателей. В рецензиях и обзорах писатель четко выражает свою позицию по отношению к рассматриваемому художественному произведению или изданной книге. Он резко критикует, но в то же время выступает популяризатором татарской литературы, часто обращается к творчеству молодых и начинающих писателей. Критические статьи М. Джалиля ценны своей обращенностью к истории татарской литературы, к вопросам творческого мастерства. Они позволяют по-новому взглянуть на все творческое наследие поэта.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, литературная критика, татарская литература советского периода, Муса Джалиль, жанры литературной критики

The article is devoted to the study of the literary-critical legacy of the famous poet-hero Musa Jalil. Despite the fact that the poetic work of the writer has been studied quite thoroughly, the activity of M. Jalil as a literary critic was considered only in a few articles published in periodicals in the 80s of the last century. The authors of these publications are R. Mukhamadiev, Sh. Khamatov, A. Makhmudov, R. Mustafin. This article aims to summarize the available information about the poet's activity in this area and briefly characterize his literary-critical legacy outside the framework of any socio-political phenomena. The novelty of the study lies in the fact that M. Jalil's articles allow us to take a fresh look at some features of the literary process of the Soviet period; they reflect the everyday life of Soviet writers. In reviews and over views, the writer clearly expresses his position in relation to the work of art or published book under consideration. He is a sharp critic, yet also a popularizer of Tatar literature, often addressing the work of young and emerging writers. M. Jalil's critical articles are valuable for their focus on the history of Tatar literature and issues of creative mastery. They allow one to take a fresh look at the poet's entire creative legacy.

**Keywords:** history of Tatar literature, literary criticism, Tatar literature of the Soviet period, Musa Jalil, genres of literary criticism

Күренекле татар шагыйре Муса Җәлил иҗатының төп өлеше поэзиягә бәйле булса да, әдип тәнкыйтьче буларак та татар совет әдәбияты үсешенә үзеннән өлеш кертә. Шагыйрьнең әдәби-тәнкыйди мирасын аерым мәкаләләрдә Р. Мөхәммәдиев, Ш. Хамматов, Ә. Мәхмүдов, Р. Мостафин тикшерә, әмма алар барысы да бу юнәлештә аерым бер эзләнүләр алып барылырга тиешлекне ассызыклый. Әлеге галимнәрнең хезмәтләре узган гасырның 80 нче елларында вакытлы матбугат битләрендә урын алган, ягъни М. Җәлилнең ил күләмендә булып узган иҗтимагый-тарихи вакыйгаларга бәйле тәнкыйть язмалары яңача бәяләүне көтә.

Герой-шагыйрьнең биш томлы әсәрләренең 5 нче томына кырыктан артык тәнкыйди мәкалә урнаштырылган. Аларның күпчелеге «Коммунист» газетасында бастырылган, шулай ук «Эшче», «Татарстан» газеталарында, «Ударниклар», «Совет әдәбияты» журналларында, язучыларның сайланма әсәрләренә кереш сүз рәвешендә дөнья күргән язмалары да бар. Язылу вакыты буенча мәкаләләр 1924–1941 елларга карый. М. Җәлилнең әдәби тәнкыйтьтә актив эшләгән чоры дип 1931–1934 елларны атарга мөмкин.

«Муса Җәлилнең тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге әдәбиятта РАПП карашлары үсеш алган һәм вульгар социологик юнәлеш киң таралган чорга туры килә», – дип билгели Р. Мостафин [4: 179]. Шагыйрьнең «Балалар әдәбиятына ярдәмгә» дип аталган беренче тәнкыйть мәкаләсе 1924 елда «Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының 11 февраль санында «Муса» имзасы белән дөнья күрә. Әлеге кыска гына язма Татар-башкорт бюросының бөтен татар бюроларына тараткан циркулярыннан алынган һәм татар телендә «Кечкенә иптәшләр» дип исемләнгән балалар журналы чыгарырга әзерлекнең башлануы турында хәбәр итә. Билгеле булганча, 1927–1933 елларда шагыйрь Мәскәүдә комсомол эшендә катнаша, Мәскәү дәүләт университетының әдәбият факультетын тәмамлый: «…1927 елдан 1931 елга чаклы 1 нче Мәскәү дәүләт университетының (I МГУ) әдәбият факультетында укыдым һәм аның тулы курсын тәнкыйть циклы буенча тәмамладым» [1: 250]. Университетны тәмамлаганнан соң, шагыйрь журналистлык эшчәнлеген киң җәелдерә. Ул Мәскәүдә чыккан «Эшче», «Коммунист» газеталарында, «Ударниклар» журналында тәнкыйть һәм публицистик язмаларын бастыра, Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясендә (МАПП) актив эшли. М. Җәлилнең журналистлык эшчәнлеген җентекле тикшергән галим Ш. Хамматов шагыйрь аеруча «Коммунист» басмасы белән тыгыз бәйләнгән дип билдерә: «Гомумән дә аның журналист, тәнкыйтьче, шагыйрь буларак зур мәйданга чыгуы «Коммунист» газетасында эшләгән елларга туры килә, дип әйтсәк, хакыйкатькә хилафлык килмәс. Бу дәвердә газетаның редколлегия члены, танылган журналист Муса – Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясенең (МАПП) татар секциясендә өченче секретарь да була. Ул Мәскәү стена газеталары редколлегия члennары, эшчеләр белән очрашулар үткәрә, әдәби сәхифәләр оештыра,

тәнкыйть-библиография, әдәбият мәсьәләләренә карата мәкаләләр, өлкә, край, республика газеталарына күзәтүләр яза» [7: 132].

М. Җәлилнең яңа җәмгыять, социализм төзүдә актив катнашуы аның тәнкыйди мәкаләләрендә аеруча калку күренеп тора. Әлеге язмаларның атамаларына гына игътибар итик: «Без партия һәм комсомол чакырган фронтта», «Революцион әдәбият өчен киң походка», «Кызыл караван», «Яшь агитатор, пропагандист һәм оештыручы» һ. б. Билгеле, мәкаләләрдә шагыйрь яңа иҗат ысулы белән иҗат итәргә чакыра, яңа тормыш кору турында хыяллана. Бер үк вакытта әдәбиятны марксизм нигезендә тикшерергә өнди [1: 15]. «Совет драматургиясе яңа чорда» мәкаләсендә китерелгәннәргә таянып, әдәбият галиме Ф. Мусин «социалистик реализмны аңлатуда Г. Ибраһимовка М. Җәлил шактый якын тора, – дип белдерә, – ...ул бу метод әдәбиятның “социализм чорының бөтен дөреслеген, бөтен катлаулылыгын ачып күрсәтергә” тиешлеге турында яза, партиялелек принцибына аеруча игътибар бирә» [6: 485].

Пролетариат әдәбияты гегемониясе өчен көрәш алып барганда, шагыйрь матур әдәбиятка карата үз билгеләмәсен тәкъдим итә: «Матур әдәбият тормышның көзгесе генә түгел, матур әдәбият – үзе торган сыйныфның тормышка, кешеләр арасындагы катнашка, бәйләнешкә үз теләгенчә билгеле бер үзгәреш кертә торган, йогынты ясый торган коралы» [1: 14]. Фикерен дәвам итеп, М. Җәлил әдәбияттагы диалектика законнары турында уйлана, бу юнәлештә әдәбият тарихчылары Г. Сәгъди һәм Х. Вәлиләрне тәнкыйтьләп чыга («Матур әдәбиятыбыз алдындагы үзәк проблемалар»). Әлбәттә, биредә М. Җәлилнең социализм пропагандасы белән артык мавыгуы, вульгар социологизм карашларын үз итүе дә чагылып китә. Моның ачык мисалы – «Ике шагыйрь турында» мәкаләсе. Тәнкыйтьче Җәлил әлеге язмасында Һ. Такташ белән М. Крыймов иҗатларын чагыштырып карый, соңгысының иҗат үрнәкләрен өстен куя. Әмма алга таба инде тәнкыйтьче бу юлда нигезлерәк уйлана башлый, Такташ турындагы фикерләрен дә үзгәртә, аның «тирән иҗат көче»н таный. Ул «...социалистик реализм әдәбиятының “коры өндәү методын корал итмәскә… җанлы сурәтләр, җанлы характерлар аша, үзенең художество чаралары аша чынлыкны бирергә” тиешлеге турында яза» [6: 484]. М. Җәлил башкаларның иҗатларына таләпчән була белгән кебек, үз эшчәнлеген дә һәрдаим тәнкыйди караш аркылы үткәрә, бу исә аның бертуктаусыз эзләнүдә, фикер сөрешенең үсештә булуын ассызыклый.

Шагыйрьнең беренче тәнкыйть язмалары коры пропаганда, агитация төсендә кабул ителсә, тора-бара тәнкыйтьченең үз стиле, үз анализ рәвеше формалашуын күрәбез. Ул инде бары тик яңа иҗат ысулына таянып кына түгел, ә бәлки сәнгатьнең үз законнарын да күздә тотып иҗат итәргә чакыра: «Ударникларның күпчелегенә уртак булган төп җитешсезлекләрнең беренчесе – сурәттә ярлылык, сурәт өстендә нык эшләмәү, үзе әйтергә теләгән идеяне бай, реаль, тулы сурәт аркылы җанландырудан качып, шаблон фразалар аркылы бирергә ашыгу. Бик дөрес, тотнаклы, бай идеяләр дә, әгәр дә тулы

реаль сурәт аркылы бирелмәсәләр, әдәби кыйммәтләрен югалталар» [1: 51]. Шунысын да билгеләп үтү мөһим: социалистик реализм методы турында сүз йөрткәндә, М. Җәлил *стиль* сүзен куллана, әдәбият тарихына кереп киткән «уңай» геройны *иҗаби* сүзе белән сыйфатлый. Әлеге күренешләр барысы да совет чоры тәнкыйтенең формалашу чорында эзләнүләр юлыннан баруы турында сөйли.

«1933–1934 еллар – Җәлилнең әдәби тәнкыйть эшчәнлеге чәчәк аткан чор. Бу вакытта аның иҗатында поэзия түгел, ә тәнкыйть өстенлек ала. Кайбер айларда ул ун-унбишәр мәкалә һәм рецензия яза – ике елда гына да әдәбият мәсьәләләренә караган барлык материалларының яртысы диярлек язылган» [4:184]. Алар арасында күзәтү мәкаләләре, аерым бер әсәр яисә китап басылу уңаеннан язылган рецензияләр, язучыларның юбилей даталарына бәйле язмалар, китапларга кереш сүз буларак тәкъдим ителгән мәкаләләр бар. Соңгысына мисал итеп Г. Тукайның 1938 елда нәшер ителгән сайланма әсәрләренә «Сүз башы»н китерергә мөмкин. «Г. Тукай үзенең тулай халык хәрәкәтендә уйнаган шушы иҗаби-прогрессив роленнән тыш, – дип яза М. Җәлил, – әдәбият тарихында тоткан урыны һәм әдәби хезмәтләре белән аеруча игътибарга хаклы шагыйрь» [1: 138]. Бөек шагыйрьне ул татар әдәби телен тудыручы һәм үстерүче, татар матур әдәбиятын тудыручы, татар әдәбиятында политик лириканы нигезләүче, сатира һәм юморга үткен һәм оста әдип, татар балалар әдәбиятын тудыручы, рус һәм Европа классик әдипләрен татар әдәбиятына башлап кертүче, халыкка якын язучы буларак данлый.

М. Җәлил үзенең рецензияләрендә Ш. Шәһәретдинов, М. Галәү, М. Әмир, С. Урайский, А. Алиш, А. Әхмәт, Х. Госман, Һ. Дәүләтшина һ. б. китапларына, әсәрләренә мөрәҗәгать итә, яшь язучыларның әсәрләрен анализлый. Әлеге язмаларда социалистик реализм методына таянып эш итү дә, язучыларның образ-типларын сурәтләүдә уңыш-табышлары, кимчелекләре дә читтә калмый. Мисал өчен, «Чакырылучы ударникларның иҗатлары турында берничә сүз» мәкаләсендә М. Җәлил әдәби әсәрләрнең теле, тел-стиль мәсьәләләренә дә туктала: «Безнең яшь шагыйрьләрдә әле менә шул сурәтләү чаралары (средстволары), охшату осталыклары җитешми. Алар өлкән язучыларның бай әдәби материалларыннан шул ягын җентекләп, нык өйрәнә алалар. Ләкин монда, тәнкыйтьсез өйрәнеп, иске охшатуларга иярү дә ярамый... Ударникларның күпчелегендә тел ярлылыгы да күзгә бәрелә. Күп язучыларда ялгыш җөмләләр, оешмаган фразалар очрый, кытыршы юллар, үлчәме, рифмасы килмәгән шигырьләр туры килә» [1: 53]. М. Җәлил яшьләр һәм балалар өчен язылган әсәрләргә аеруча игътибарлы, яшь язучылар иҗатына да битараф кала алмый («Совет балалар әдәбиятына иң нык игътибар!», «Яшьләр әдәбиятын – югары баскычка»). Әдәбиятчы Г. Кашшаф язганча: «Аның тәнкыйть принциплары Москва язучыларының әдәби әсәрләрен конкрет алып тикшергәндә тагын да ачыла төшә. Ул Г. Ильясның “Штык” романын, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй һ. б. язучыларның художество дәреслегеннән читкә китү очракла-

рын тәнкыйть итә һәм бу тәнкыйтьтән ул үзен дә читтә калдырмый» [2: XLV]. Шагыйрьнең юбилейларга мөнәсәбәтле язылган күләмле мәкаләләре Ш. Камал, М. Гафури, В. Маяковскийларга багышлана.

М. Җәлилнең киң карашлы, принципиаль һәм таләпчән тәнкыйтьче булуын аның күзәтү мәкаләләре раслап тора. Беренче язмаларыннан ук ул әдәбият алдында торган бурычлар, проблемалар турында уйлана, үз фикерләрен дәлилләп, нигезләп язып чыга. Мисал өчен, яңа чорда иҗат ителгән совет драматургиясен ул әдәби иҗатның мөһим бер төре буларак таный һәм драма әсәрләренең башка жанр әсәрләрдән өстен якларын аерып чыгара. Бер үк вакытта ул татар әдәбиятында бу төрдә язылган әсәрләрдәге җитешсезлекләрне күрсәтеп бирә: «Бездәге әсәрләрдә зур җитешсезлекләрнең берсе – бөтен мәсьәләләрне бер әсәргә тыгарга тырышу, бөтен типларны бер әсәрдә бирергә омтылудан гыйбарәт. Бездә нинди генә темага булсын бер әсәр язылаикән, анда вредительлек тә, ярыш та, ударниклык та, икмәк җыю да, техника өчен көрәш тә, интеллигенцияне безгә таба бору да – бар да, бар да керергә тиеш булып чыга... Менә шулай итеп, безнең әсәрләрнең күбесе, бөтен кампанияләрне һәм типларны җыйнап алам дип, шаблонга әйләнәләр дә калалар» [1: 79].

М. Җәлилнең «Югары сыйфат өчен көрәшкәндә» дигән мәкаләсе Татарстан Совет язучылары союзы правлениесенең отчёт докладыбуларак тәкъдим ителә. Оешманың ел ярымлык эшенә йомгак ясаганнан соң, тәнкыйтьче игътибарны язучылар алдында торган төп бурычларга юнәлтә. Шулар арасында ул яшь һәм башлап язучылар белән эшләүне иң мөһим тармакларның берсе итеп саный, әлеге төркемгә кергән иҗат әһелләренең «күп беләмлек» чире, «иртә профессионализм» белән авыруларын тәнкыйтьләп чыга. Бер үк вакытта ул барлык язучыларга карата түбәндәге сүзләрне җиткерә: «Без үзебезнең иҗат хезмәтебезне оештыра белмибез. Үз хезмәтебезнең сыйфатына ныклы таләп кую, намуслы мөнәсәбәт җитми. Без күбесенчә ашыгабыз, кабаланабыз, халтурага биреләбез; әсәрне кат-кат җентекләп эшләргә иренәбез. Безнең арада шулай ук бер-беребезнең уңышы өчен тырышмау, хәтта көенү, гайбәт, тәнкыйтьтән курку, бушка вакыт үткәрү һ. б. әле бетеп җитми. Бу нәрсәләр безнең арада тормышыбызның һәм эшебезнең бөтен ягын эченә ала торган зур тәрбия эше кирәклеген күрсәтәләр» [1: 214]. Әлеге саллы мәкаләсендә автор аерым төрләрдә актив иҗат итүче язучыларның әсәрләренә туктала, аларга карата үз фикерен җиткерә. Аның милли әдәбият турында уйланулары да кызыклы яңгырый. Милли форма үзенчәлеген билгеләп, ул милли телгә хас «образлылык, традиция аша буыннан буынга бирелә килгән, бигрәк тә фольклорда сакланган стилистик формалар һәм алымнар» хакында әйтә. Тәнкыйтьче шулай ук милли әдәбиятларны укыту мәсьәләсенә дә кагылып уза. «Педагогия училищелары өчен төзелгән татар әдәбиятын укыту программасы проекты турында»гы бәяләмәсе шул хакта сөйли. Биредә М. Җәлил татар әдәбиятының аерым чорлары (Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы) программадан төшеп калганы, татар әдәбияты тарихында зур урын

алган аерым бер әсәрләргә, шәхесләрнең иҗатына (Ш. Зәки, Ф. Халиди, Ш. Мөхәммәдев һ. б.) урын табылмаганы өчен борчылып яза [1: 173]. Программада тәнкыйть һәм татар тәнкыйтьчеләре турында бер сүз булмавына да аерым тукталып уза [1: 175].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, герой-шагыйрьнең әдәби тәнкыйть эшчәнлеге шактый киң һәм күпкырлы булуын күрәбез. Әдипнең әдәби тәнкыйтен аның сәнгать буенча язылган мәкаләләре белән бәйле өйрәнү дә кызыклы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Тәнкыйтьче М. Җәлил һәрчак эзләнгән, ул татар әдәбиятының үсешен кайгырткан. Бу юлда төрле адымнар ясаса да, шагыйрь үз хаталарын таный белгән, аларны төзәтергә омтылган һәм үзенә дә, башкаларга кебек үк, катгый таләпләр куеп эш иткән. М. Җәлилнең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге иҗатын тикшергән Ә. Мәхмүдов үз заманында күтәрелгән проблемаларга карата әлеге мәкаләләрнең актуаль һәм мөһим булуын күрсәтә, шагыйрь илнең күпхалыклы әдәбиятлары турында сүз йөрткәндә милли язучылар алдында торган бурычларга да кагылып узганын билгели [3: 158]. Шагыйрьнең тәнкыйди мирасын өйрәнгән Р. Мөхәммәдиев исә М. Җәлил тәнкыйтендә калку чагылган гражданлыкны аерып чыгара [5]. Каһарман шагыйрьнең әдәби тәнкыйте алга таба да чор әдәби хәрәкәте фонында һәм бүгенге заман әдәбият белеме таләпләреннән чыгып өйрәнелергә тиеш.

**Әдәбият**

1. *Җәлил М.* Әсәрләр: 5 томда. 4 т.: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм биографик материаллар. 2006. 318 б.

2. *Кашшаф Г.* Шагыйрь һәм батырлык (Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗат юлы) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 1 т. / төз. Ә. Җәлилова; Г. Кашшаф ред., сүз башы һәм иск. белән. Казан: Таткнигоиздат, 1955. Б. VII–LXXXVI.

3. *Мәхмүдов Ә.* Муса Җәлилнең тәнкыйть эшчәнлеге // Казан утлары. 1974. № 8. Б. 155–159.

4. *Мостафин Р.* Җәлил – әдәби тәнкыйтьче // Казан утлары. 1984. № 2. Б. 179–187.

5. *Мөхәммәдиев М.* Тәнкыйтьче-гражданин // Социалистик Татарстан. 1986. 14 февраль.

6. *Мусин Ф.* Әдәбият белеме һәм тәнкыйть / Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 4 т.: Татар совет әдәбияты (1917–1941). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 482–499.

7. *Хамматов Ш.* Муса Җәлил – журналист, тәнкыйтьче // Казан утлары. 1981. № 5. Б. 129–138.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Галиева Ляйсан Шаукатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*nisanbedri@mail.ru*